Сайфуллин Дамир
Раянович
C=RU, O="МОУ ""
Кульбашинская основная
общеобразовательная
школа""", CN=Сайфуллин
Дамир Раянович,
E=kulbash-shkola@rambler.
ru
я подтверждаю этот
документ своей
удостоверяющей
подписью
д.Кульбаш
2023.11.11 13:52:00+03'00'

**МОУ «Кульбашинская основная общеобразовательная школа»**

**Утверждаю:**
**Директор школы**
**___________/Сайфуллин Д.Р./**
**2023**
**«_____»_________2023 г.**

**Рассмотрено на заседании ШМО**
**учителей-предметников**
**Протокол №1 от 5 сентября**

**___________ /Хасанова М.Ш./**

# Рабочая учебная программа
## по родной литературе
## для 5 класса

**Составила: Файзрахманова Радина Ильдусовна - учитель родной литературы**

**2023/2024 учебный год**

## Аңлатма язуы.

## Эш программасы статусы.

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:
1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы.
- 6 статья – белем алу теле (телләре)
-10 статья –уку-укыту программалары
- 32 статья – мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы.
3. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
4. Дәреслек: 5 нче сыйныф өчен Ф.Ф.Исламов, Ә.М.Закирҗанов тарафыннан эшләнгән “Татар әдәбияты” дәреслеге (Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009нчы ел)

## Әдәбият укытуның максаты һәм бурычлары.

Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү.
Балаларны гомумән татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.
Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, чит илләрдәге милләттәшләребез тормышы турында мәгълүматлар бирү.
Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшьүсмерләрдә Ватанга, халыкка, туган илгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек , шәфкатьлелек тәрбияләү. Шулай ук хезмәт тәрбиясе һәм эстетик тәрбия бирү.
Аңлашыла ки, бу бурычлар, аерым-аерым күрсәтелсәләр дә, үзара тыгыз бәйләнгәннәр. Алар бердәм уку-укыту процессында гамәлгә ашырылалар, чөнки дәрестә белем бирү, шәхес формалаштыру бергә бәйләп алып барыла.
Программага әсәрләр киләчәк яшь буынны мәрхәмәтле, шәфкатьле, туган як табигатен саклаучы һәм яратучы, кешелекнең уңай сыйфатларына ия булган, милләт мәнфәгатьләрен яклардай кеше итеп тәрбияләү бурычларын күз алдында тотып сайланды.
Укучыларга рухи, милли һәм әхлак тәрбиясе бирүдә, аларны халкыбызга хезмәт итәрдәй шәхес буларак формалаштыруда бу әсәрләрнең роле зур. Яшь буынга милли яшәү рәвешен җиткерүдә, аның үзаңын үстерүдә, бу юнәлештә гамәли адымнар ясауга әзерләүдә әдәбият мөһим җирлек булып тора.
Башлангыч сыйныфлардагы әзлеклелекне дәвам иттереп, укучыларның белемнәрен тулыландыру максатыннан, халык авыз иҗатыннан да үрнәкләр алынды. Беренчедән, алар укучыларга фольклордан тулырак мәгълүмат бирә, икенчедән, телгә караган белемнәрне гамәли яктан ныгыту өчен материал буларак кулланыла.
Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны сәнгатьле уку алымнарына өйрәтү дә әһәмиятле. Бу җәһәттән эш түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла:
• татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтү күнекмәләре булдыру;
• суз басымын дөрес куя белү;
• логик басымны дөрес куя белү;
• җөмләне фразаларга бүлү һәм дөрес пауза белән уку;
• тавышны дөрес төшерә һәм күтәрә белү, интонацияне дөрес куллана белү күнекмәләре булдыру һ. б.

Программада ятлау өчен әсәрләр, сөйләшү тематикасы, сыйныфтан тыш уку тематикасы тәкъдим ителә, укучыларның уку сыйфатын билгеләү максатында әдәби әсәрләр белән эшләүгә, әдәбият теориясеннән белем-күнекмәләр булдыруга таләпләр бирелә.
Матур әдәбиятны, шул рәвешле, төрле яклап өйрәнү һәм үзләштерү укучыларның сөйләм һәм язу күнекмәләрен камилләштерүгә ярдәм итә. Болар һәммәсе урта белемгә ия булган яшьләр ана телендә фикерли, иркен сөйләшә, дөрес яза белергә тиеш дигән максатка ирешергә ярдәм итә.

## Яңа уку елы башына укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә кыскача характеристика.

1. Аңлап, йөгерек, сәнгатьле уку, уку тизлеге 1 минутка 65-75 сүздән ким булмаска тиеш. Аңлап һәм эчтән шома уку күнекмәләренә ия булу. Дөрес, тиешле тон һәм интонацияне сайлап, сәнгатьле уку ярдәмедә текстның эчтәлеген төшендерә алу.
2. Укылган кисәккә сайлап баш куя белү.
3. Текстны мәгънәви яктан бәйле кисәкләргә бүлә белү, план төзи белү.
4. Текстның эчтәлеге буенча сораулар куя белү.
5. Укытучының ярдәмендә персонажга бәя бирә белү.
6. Балалар тормышына якын әсәрләрне укытучы ярдәмендә дәвам итә белергә тиеш, иҗади эшли белү.
7. Хикәяләр, андагы вакыйгалар бирелешен, персонажларның холкы, эш- гамәлләрен белү.
8. Халык авыз иҗаты. Аның төрләре турында алдагы сыйныфта өйрәнгәннәрне ныгыту.
9. Әдәп- әхлак темасына багышланган әсәрләрдән яхшы сыйфатларны сайлап ала белү.
10. 4нче сыйныфлар өчен бирелгән якынча лексик-фразеологик минимумны белү.

## 5нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр.

1. Әкиятләр, аларның төрләрен, геройларның төп сыйфатларын аера белү. Язучылар язган әкиятләрнең үзенчәлекләрен белү.
2. Мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, шарадалар һәм укучыларның тапкырлыгын, зирәклеген билгеләүдә аларның ролен аңлау.
3. Хикәя жанрының үзенчәлеген белү. Әдәби әсәрнең сюжетын тотып ала белү. Әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү.
4. Уңай герой, лирик герой төшенчәләрен аера белү.
5. Өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү.
6. Классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру.
7. Әдәби текстны кабул итү, укыган буенча план төзү.
8. Геройларга характеристика бирү.
9. Укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку.
10. Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау.
11. Аңлап, йөгерек, сәнгатьле уку, уку тизлеге 1 минутка 70-80 сүздән ким булмаска тиеш. Аңлап һәм эчтән шома уку күнекмәләренә ия булу. Дөрес, тиешле тон һәм интонацияне сайлап, сәнгатьле уку ярдәмедә текстның эчтәлеген төшендерә алу.

**Укытуның тематик планы**

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать<br><br>саны |
|---|---|---|
| 1 | Халык авыз иҗаты. Аның жанрлары.“Зирәк карт” әкияте.“Җил арба” әкияте. Мәкальләр , әйтемнәр, табышмаклар, шарадалар, тизәйткечләр. | 5 |
| 2 | Габдулла Тукайның ”Сабыйга “ , “ Эш беткәч уйнарга ярый“ ”Ана догасы”, “Эшкә өндәү “, “Су анасы” шигырьләре,” Һәр нәрсәнең үз урыны бар “ хикәясе. | 4 |
| 3 | Әнвәр Бакиров. | 1 |
| 4 | Скульптор Садри Ахун | 1 |
| 5 | Әхмәт Фәйзи. Тормыш юлы турында белешмә. «Тукай» романы (өзек). | 2 |
| 6 | Нәҗип Думавиның тормыш юлы турында кыскача белешмә. Н.Думави “Айлы төн” , “Син – кеше” шигырьләре | 2 |
| 7 | Нәкый Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Н.Исәнбәтнең“Туган ил”, ”Син сазыңны уйнадың” шигырьләре . | 2 |
| 8 | Гаяз Исхакыйның тәрҗемәи хәле. «Кәҗүл читек» хикәясе. | 3 |
| 9 | Мәҗит Гафуринең тормыш юлы турында белешмә. М.Гафуриның “Гөлләр бакчасында” шигыре, “ Кыр казы” хикәясе. | 3 |
| 10 | Галимҗан Ибраһимовнең тормыш юлы турында кыскача белешмә, “Яз башы” хикәясе. | 3 |
| 11 | Дәрҗия Аппакованың Тормыш юлы турында белешмә. «Йолдызкай», “Шыгырдавыклы башмаклар” хикәясе. | 2 |
| 12 | Гөлсем Сөләйманова. | 1 |
| 13 | Фатих Кәримнең тормыш юлы турында белешмә. «Гармунчы аю белән җырчы Маймыл» әкияте,“Үлем уены” поэмасы . | 3 |
| 14 | Абдулла Алишның тормыш юлы турында белешмә. «Сертотмас үрдәк» әкияте, «Чуар тавык» хикәясе. | 4 |
| 15 | Фатих Хөснинең тормыш юлы турында белешмә. «Малай белән солдат», «Сөйләнмәгән хикәя» әсәрләре. | 3 |
| 16 | Нәби Дәүлинең тормыш юлы турында белешмә. «Бәхет кайда була?» шигыре, «Кар нинди җылы» хикәясе. | 2 |
| 17 | Нури Арсланов “Казан” шигыре | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 18 | Гамир Дәүләтшин “Гасырлар тирәнлегеннән”. | 1 |
| 19 | Гомәр Бәширов “Нинди ул Татарстан?” | 1 |
| 20 | Сажидә Сөләйманова. Шагыйрәнең тормыш юлы турында белешмә. «Кайный, шаулый Казан урамнары». «Ялгыз торна» хикәясе. | 1 |
| 21 | Ырымнар. | 1 |
| 22 | Шәүкәт Галиев. Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле. «Алтын куллар», «Телләр белүче каләм», «Магнитофон онытмый» шигырьләре. | 3 |
| 23 | Рабит Батулла. Тормыш юлы турында белешмә. «Дуслар дус булып кала» әкияте (өзек). | 1 |
| 24 | Фәнис Яруллин. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. «Анам теле» шигыре. «Кояштагы тап» әкияте. | 3 |
| 25 | Солтан Шәмси. Язучы турында мәгълүмат. «Табигатьнең газиз баласы» хикәясе. | 2 |
| | Бәйләнешле сөйләм үстерү:9 сәгать | |
| | Дәрестән тыш уку: 6 сәгать | |
| | Әсәрләрне уку һәм өйрәнү: 55 сәгать | |
| | Барысы: 70 сәгать | |

## Укыту – методик комплекты

1. “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”, Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
2. 5 нче сыйныф өчен Ф.Ф.Исламов, Ә.М.Закирҗанов тарафыннан эшләнгән “Татар әдәбияты” дәреслеге . Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2009нчы ел.
3. “Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы” Д.Ф.Заһидуллина. Казан”Мәгариф” нәшрияты, 2000нче ел.
4. “Рус мәктәпләрендә татар балаларына әдәбият укыту” Ф.Ф.Исламов. Казан”Мәгариф” нәшрияты, 1996нчы ел(укытучылар өчен методик кулланма)
5. “Мәгариф” журналы.
6. “Татар балалар әдәбияты” Л.И.Минһаҗева, И.Х. Мияссарова. Казан “Хәтер” нәшрияты, 2009нчы ел.

# Укуны бәяләү.

Укучыларның 1 минутка уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:

| Класслар | Иҗек саны | Сүз саны |
|---|---|---|
| V | 130-190 | 70-80 |

**Искәрмә.** Эчтән уку тизлеге, кычкырып уку белән чагыштырганда, 5-7 нче классларда – 30-40 процентка, ә 8-9 нчы классларда 40-50 процентка югарырак була.
Уку барышында үтәлергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>- фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>- татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>- җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр – иҗекләргә, җөмлә - сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>- тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса,<br>- интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса;<br>Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | “5”ле билгесе куела. |
| 1. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфоэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә, ягъни:<br>- кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә; | “4”ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | - сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>- җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | |
| 1.<br><br>2.<br><br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br><br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | “3”ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br>3.<br><br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлегеннән аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда. | “2”ле билгесе куела. |

## Телдән җавапларны бәяләү.

Телдән җавап бирү – тәкъдим ителгән теманы сөйләү формасында була.

М а т е р и а л:

1) программа материалы буенча бирелгән яисә үзе сайлап алган тема;
2) эчтән укылган текстның (нигездә, әдәби әсәрдән яисә әдәбият дәреслегеннән алынган, күрсәтелгән яисә үзе сайлап алган) эчтәлеге.

С ө й л ә ү г ә  б и р е л ә  т о р г а н  в а к ы т:

VI - V класста 2-5 минут.

## Әдәбият дәфтәренә таләпләр

Әдәбият дәфтәрендә һәр уку елы дәвамында түбәндәге төп язмалар була:

1) планнар
**2)** эчтәлекне хикәяләп язу
**3)** цитаталар (күчереп язу)

**4)** аңлатмалар (сүз һәм төшенчәләргә)
**5)** фикер язмалары (үз фикереңне язып кую)
**6)** укучы үзе иҗат иткән әдәби әсәрләр (хикәяләр, шигырьләр, мәзәкләр, сценарийлар
**7)** халык авыз иҗатыннан җирле материаллар

Әдәбият дәфтәрендә бары тик программа материалын үзләштерүгә һәм аны язып бирә белергә өйрәтә торган язмалар гына булырга тиеш. Язма эшләр сочинение таләпләре белән бәяләнә.

## Укуга карата төп таләп – сәнгатьле уку.

<u>Уку материалы:</u>

1. Укучы үзе язган текст яки сочинение.
2. Әдәби әсәрдән, публицистик һәм фәнни хезмәттән өзек.

<u>Материалның күләме:</u>

Һәр класс өчен билгеләнгән сочинение күләме икеләтә алына.

<u>Материалны сайлап алу:</u>

1. Укучы үзе сайлый, үзе теләгән текстны укый.
2. Укытучы күрсәтмә бирә.

<u>Укуны әдәбият фәне буенча бәяләү өчен таләпләр:</u>

1. Уку тел (грамматика) фәне буенча уңай билге куярлык булсын.
2. Сәнгатьле яисә логик сәнгатьле (текстның характерыннан чыгып) башкарылсын.
3. Уку интонациясен бөтен текстка һәм аның аерым өлешләренә карата укучы аңлатып бирә белсен.

И с к ә р м ә. Уку интонациясен аңлатканда:

1. V – VII классларда интонациянең текст эчтәлегенә карата булган ягын аңлату җитә (ягъни объектив эчтәлектән чыгып).

Соңгы ике таләптән берсенең үтәлмәве тел буенча куелган билгене – бер баллга, икесенең дә кимчелекле үтәлүе билгене ике баллга кимәтә. Икесе дә бөтенләй үтәлмәгән булса, әдәбияттан “2”ле куела.

**Рус мәктәбенең 5нче Б сыйныфында укучы татар балалары өчен татар әдәбиятыннан якынча календарь-тематик дәресләр планы.**

| № п/п | Дәрес темасы | Сәг. саны | Дәрес тибы | **Укучылар эшчәнлегенә характеристика** | Контроль төре | **Материалны үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре** | Өй эше | Дата План | Дата Факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Туган ягым – Татарстан. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | Татарстан турында белемнәрне тулыландыру . Туган җирне ярату, саклау. | | Сөйләм телен үстерү. | Рәсем ясарга | | |
| 2 | Кереш дәрес. Халык авыз иҗаты. | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Халык авыз иҗаты турында мәгълүмат бирү, аның жанрлары, әкиятләр жанры турында төшенчә бирү. Көнкүреш әкиятләре. Хайваннар турындагы әкиятләр. Тылсымлы әкиятләр. Уртак сыйфатлары, аермалары. Әңгәмә. | | Тел культурасын баету, фикерләү сәләтен үстерү. Халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү аша матур әдәбият дөньясына керергә әзерләү. | Үзләре белгән әкият исемнәрен язып килергә | | |
| 3 | “Зирәк карт” әкияте . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Әкиятнең эчтәлеге белән танышу, рольләп уку, сүзлек эше, сорауларга җавап, укытучы ярдәме белән идеясен билгеләү, андагы образларга характеристика бирү, анализ. | | Әкият геройлары үрнәгендә шәфкатьлелек , миһербанлылык тәрбияләү Әкиятне анализлый белү. | 5-8нче бит, эчтәлек, анализ. | | |
| 4 | “Җил арба” әкияте | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Әкиятне рольләп уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, сүзлек эше, сорауларга җавап, укытучы ярдәме белән идеясен билгеләү, образларга хас уңай һәм тискәре сыйфатларны ачу. | | Өлкән кешегә ихтирамлы караш, туганлык хисе, хезмәт ярату, һөнәр үзләштерергә теләү тәрбияләргә омтылу. Әкиятне анализлый белү. | Образларга характеристика | | |
| 5 | **Татар халык әкиятләре . Кл. тыш уку.** | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү. Китапка мәхәббәт тәрбияләү, әкиятләр уку белән кызыксын-дыру, мөстәкыйль укуга күнекте-рү. Әсәр турында үз фикерен | | Сөйләм телен үстерү. Эчтәлек сөйли белү.. | Берәр әкият сөйләргә | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | сөйләп бирә белү сәләтен үстерү. | | | | | |
| 6 | Мәкальләр , әйтемнәр . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Мәкальләр , әйтемнәр турында төшенчә, аларның табигатенә хас төп сыйфатлар; аларның тел-бизәк , сөйләмнең тәэсирлеген көчәйтү чаралары булуы ,уку, сүзлек эше, мәкальләр белән уен. | Мәкальләр язып килергә. | Сөйләм телен мәкальләр һәм әйтемнәр белән баету. | 10 мәкаль язып килергә. | | |
| 7 | Табышмаклар, шарадалар, тизәйткечләр. | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү.Табышмаклар, шарадалар, тизәйткечләр турында төшенчә, уку, сүзлек эше, табышмак әйтеш уены. | Табышмаклар язып килергә | Сөйләм телен баету. Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. | Табышмаклар җыеп кулъ-язма китап әзерләргә | | |
| 8 | **Табышмаклар ярышы. Б.с.ү** | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү.Уен – дәрес . Балаларның зиһенең, тапкыр-лыгын , фикерләү сәләтен үстерү | | Сөйләм телен баету. Уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. | | | |
| 9 | Г . Тукай – балалар язучысы. ”Сабыйга “ шигыре . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Тормыш юлы турында сөйләү, Тукай яшәгән урыннарның схема-планын төзү, сүзлек эше, әсәрләре белән тирәнтен танышу, сәнгатьле уку, шигырьне өлешчә анализ-лау. Шигырь турында төшенчә. | Шигырьне ятлау. | Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру. Шигырьне яттан белү. | 28нче бит, шигырьне ятларга | | |
| 10 | Г.Тукай “ Эш беткәч уйнарга ярый“ , “Эшкә өндәү “ шигырьләре. | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Шагыйрьнең бала психологиясен сурәтләве , мәгърифәткә , яшьләргә белем һәм тәрбия бирүгә мөнәсәбәте, сүзлек эше, сәнгатьле уку, текст белән эш. | Шигырьне ятлау. | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьне өлешчә анализлау. | 29-31нче бит, сәнгатьле уку, шигырьне ятларга | | |
| 11 | Г . Тукай “ Су анасы “ . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Рольләп укырга өйрәтү, эчтәлек буенча фикер алышу, сүзлек эше, сорауларга җавап, план төзү. | | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. План төзи белү. | План нигезендә экиятне сөйләргә(29-31) | | |
| 12 | Г.Тукай ”Ана догасы”, “ Һәрнәрсәнең үз урыны бар”. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү.Сәнгатьле уку, шигырьнеөлешчә анализлау, сорауларга җавап. | | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. | Сәнгатьле уку | | |
| 13 | Ә. Бакировның тормыш юлы, иҗаты . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә. Балет төшенчәсе . Уку, сүзлек эше. Балет музыкасыннан | | Татар композиторының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Татар музыкасын үстерүдәге | 35-36нчы бит, сорауларга җавап | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | өзек тыңлау. | | роле. | | | |
| 14 | Скульптор Садри Ахунның тормыш юлы, иҗаты . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү.Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Рәсем сәнгатен үстерүдә аның хезмәтләре. Сүзлек эше, сайлап уку, әңгәмә, хронологик таблица төзергә өйрәтү. | | Татар скульпторының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Татар сынлы сәнгатен үстерүдәге роле. Хронологик таблица төзү | Хронологик таблица төзү (35-36) | | |
| 15 | Ә .Фәйзинең тормыш юлы, иҗаты . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Сүзлек эше, уку, эчтәлек сөйләү. | . | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Татар әдәбиятын үстерүдәге роле. | 41-42нче бит, эчтәлек | | |
| 16 | Ә.Фәйзи “Тукай” романы . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү. Уку, аның төрләре, эчтәлек буенча фикер алышу, портрет турында төшнчә бирү, сурәтләү чараларын табу. Тукайның балачагы һәм язмышының халык тормышына бәйлелеге. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. | 52-54нче бит, эчтәлек | | |
| 17 | **Г.Тукай музеенда. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү.Тормыш юлы һәм иҗаты турында белгәннәрен арттыру. Ведиофильм карау. Фикер алышу, әңгәмә. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. | Рәсем ясарга, Г.Тукайның иҗатын кабатларга | | |
| 18 | **Ә.Фәйзи “Тукай”романы . Кл. тыш уку.** | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү. Китапка мәхәббәт тәрбияләү, китаплар уку белән кызыксындыру, мөстәкыйль укуга күнектерү. Әсәр турында үз фикерен сөйләп бирә белү сәләтен үстерү. | Тест. Г. Тукай. (10мин) | Өйдә мөстәкыйль уку. Кызык-лы урыннарын сөйләү. | Өзекне яттан сөйләргә | | |
| 19 | Н. Думавиның тормыш юлы , иҗаты . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, сүзлек эше, уку, эчтәлек сөйләү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Татар әдәбиятын үстерүдәге роле. | Хронологик таблица төзү (56-57) | | |
| 20 | Н.Думави “Айлы төн” , “Син – кеше” шигырьләре . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү.Сәнгатьле һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру, сурәтләү чараларын табу, сорауларга җавап бирү. Табигатьнең матурлыгын сурәтләү, кешене бөек зат буларак бәяләү . | шигырь ятлау | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьне өлешчә анализлау. Матурлыкны шагыйрь күзе белән күрергә өйрәнү. | 57нче бит, шигырь ятлау | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Н .Исәнбәтнең тормыш юлы , иҗаты . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Иҗаты турында белешмә бирү, сүзлек эше, уку, эчтәлек сөйләү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. | 60-61нче бит, сорауларга җавап | | |
| 22 | Н.Исәнбәт “Туган ил”, ”Син сазыңны уйнадың” шигырьләре . | 1 | Катнаш | Өй эшен тикшерү.Сәнгатьле һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру, сурәтләү чараларын табу, сорауларга җавап бирү. Туган як, Туган илгә мәхәббәтнең сурәтләнүе . | | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьне өлешчәанализлау. Матурлыкны шагыйрь күзе белән күрергә өйрәнү. | 62-63нче бит, сәнгатьле уку | | |
| 23 | Г .Исхакыйның тәрҗемәи хәле . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Тормыш юлы һәм иҗаты турында төшенчә. Сүзлек эше, дәреслектән уку, план төзү, монологик сөйләм күнегүләре. Хикәя турында төшенчә. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Татар әдәбиятын үстерүдәге роле. | 65-66нчы бит, эчтәлек | | |
| 24 | Г .Исхакыйның “ Кәҗүл читек” хикәясе . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Өй эшен тикшерү. Сүзлек эше, уку(аның төрләре), эчтәлеген аңлау, читекне тасвирлау, монологик сөйләм күнегүләре. | Читек рәсемен ясарга . | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. Образга характеристиа бирә белү. | 74нче бит, сорауларга җавап. | | |
| 25 | Г .Исхакыйның “ Кәҗүл читек” хикәясе . Образга характеристика. | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү. Образларга характеристика, бүлекләргә исем кую. Әсәрдә бала психологиясенең бирелеше | | Образга характеристиа бирә белү. | Әхмәдуллага характеристика | | |
| 26 | **Безнең якның ерак тарихы. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | Өй эшен тикшерү. Туган якның тарихы турында белгәннәрне тулыландыру. Туган җирне ярату, аны саклау. | | Сөйләм телен баету. | Рәсе ясарга. | | |
| 27 | М . Гафуринең тормыш юлы, иҗаты . М.Гафури “Гөлләр бакчасында” шигыре . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Сүзлек эше, текст белән эш(пауза, логик басым төшкән сүзләрне билгеләү һ.б.), уку(аның төрләре). Хезмәтнең тормыштагы роле мәсьәләсенең куелышы. | Хезмәт темасына караган мәкальләр язып килергә | Язучының тормыш юлы иҗатының төп фактларын калдыру.Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьне анализлау | 80нче бит, сәнгатьле уку, мәкальләр язып килергә | | |
| 28 | М.Гафури “ Кыр казы” хикәясе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, уку, эчтәлеген аңлау, Ак күлне сурәтләү чараларын табып , дәфтәргә язу. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән | 87нче бит, сорауларга җавап | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. Образга характеристиа бирә белү. | | | |
| 29 | М.Гафури “ Кыр казы” хикәясе . | 1 | Материалны ныгыту. | Сайлап уку, план төзү, төп геройга характеристика. Укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү . | | Лексиканы белү. Сөйләм телен баету. Образга характеристиа бирә белү. | Геройга характеристика | | |
| 30 | **“Минем яраткан йорт хайваны”. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | Сүзлек эше, әңгәмә, сорауларга җавап, укучыларның чыгышы. | Сочинение | Сөйләм телен үстерү. Бәйләнешле фикерле белү сәләтен, дөрес җөмләләр төзү осталыгын үстерү. | Сочинение язарга | | |
| 31 | Г .Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Әдипнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләү, мөстәкыйль уку, әңгәмә. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Хронологик таблица төзү. | Хронологик таблица төзү (93-94) | | |
| 32 | Г.Ибраһимов “Яз башы” хикәясе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше; аңлап уку; сурәтләү чаралары кулланып, телдән рәсем ясау. | Өзек ятлау | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. | 101нче бит, сорауларга җавап | | |
| 33 | Г.Ибраһимов “Яз башы” хикәясе. | 1 | Материалны ныгыту | Сүзлек эше, уку, хикәя турында төшенчә, сорауларга җавап. Туган як табигатенең матурлыгы, сәнгатьчә хәл ителеше | Өзек ятлау | Лексиканы белү. Сөйләм телен баету. Хикәя жанрының үзенчәлеген белү. | Өзек ятларга | | |
| 34 | **“ Туган ягым табигате”. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | План буенча кечкенә сочинение язу. | Хикәя язу | Сөйләм телен үстерү. Бәйләнешле фикерле белү сәләтен, дөрес җөмләләр төзү осталыгын үстерү. | Хикәя язарга | | |
| 35 | **Латыйфуллин “Курайчы малай”. Кл. тыш уку.** | 1 | Катнаш | Балаларны китап белән кызыксындыру. Әсәрне укып фикер алышу , курай рәсеме белән танышу . Курайда уйнаган көйне тыңлау | | Сөйләм телен үстерү. Әдәби әсәрләр белән эшләргә өйрәнү. | Өзекне сөйләргә | | |
| 36 | Д .Аппакованың тормыш юлы . “Йолдызкай” хикәясе . | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Сүзлек эше, эчтән уку, төп фикерне аңлау һәм үз сүзләре белән әйтү, сорауларга җавап. Йорт хайваннарына мәхәббәт тәрбияләү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү, текстны өлешләргә бүлү. | 108-110нчы бит, сорау. җавап | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37 | Д.Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар” хикәясе | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Уку, тестны мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне табу. Кешеләр арасында дуслык, бер – берeңә игътибарлы булу мәсьәләләренең актуальләштерелүе. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету | 110-112нче бит, эчтәлек | | |
| 38 | Г.Сөләйманованың тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Халык җырчысының тормыш юлы һәм татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәте турында белешмә. Ул башкарган җырлар язмасын тыңлау, фикер алышу. | | Җырчының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру.Татар җыр сәнгатенә керткән ролен беләү. | 114-115нче бит, эчтәлек | | |
| 39 | Фатих Кәримнең тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. Сүзлек эше, мөстәкыйль уку. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. | 116-117нче бит, эчтәлек. | | |
| 40 | Ф.Кәрим “Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әкияте. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, чәчмә һәм шигъри әсәр үзенчәлекләрен билгеләү, сәнгатьле дөрес уку күнегүләре, сүзле картина төзү. Әкияттә хайваннар образаның бирелеше. | Тест, 10мин. | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Лексиканы белү. | 117-125нче бит, сәнгатьле уку | | |
| 41 | Ф.Кәрим “Үлем уены” поэмасы. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сәнгатьле һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру, сүзлек эше, поэма жанры турында төшенчә бирү, үлемне җиңгән кечкенә солдат образы, лирик герой төшенчәләрен аера белү. | | Шигырь һәм поэманың үзенчәлекләрен белү. Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Лексиканы белү. | Образга характеристи-ка | | |
| 42 | **Хат язу. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | Хат язарга өйрәнү, фикер алышу. | Хат язу | Язма сөйләмне үстерү. | Хат язарга | | |
| 43 | А.Алишның тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Катнаш | Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә.Уку, план төзү, план буенча сөйләү. | Тест. | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. План төзи белү. | 135-136нчы бит, план нигезендә сөйләргә | | |
| 44 | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” әкияте. | 1 | Катнаш | Сүзлек эше, уку(аның төрләре), аерым өзекләрнең эчтәлеген сөйләү, хайваннарга хас сыйфатларны ачыклау, аерым өзекләрне сәхнәләштерү. Сер саклый белү. | Тест. (10мин) | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету | 136-140нчы бит, эчтәлек | | |
| 45 | А.Алиш “Чуар тавык” хикәясе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, уку ,текстның эчтәлеген күз алдына китереп , эзлекле сөйләү,хайваннар | | Лексиканы белү Текстның эч-тәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән | 146нчы бит, сорауларга җавап. | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | турындагы экиятләренең үзенчәлеге | | сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету | | | |
| 46 | А.Алиш “Чуар тавык” хикәясе. | 1 | Материалны ныгыту | Сүзлек эше, дәреслектән уку, план төзү, монологик сөйләм күнегүләре. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. | 152нче бит, сорауларга җавап | | |
| 47 | **А.Алиш “Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык” Кл. тыш уку** | 1 | Материалны ныгыту | Уку, эчтәлек, кроссворд чишү. Кошлар турында сөйләшү. | | Сөйләм телен үстерү. Әдәби әсәрләр белән эшләргә өйрәнү. | Рәсем ясарга | | |
| 48 | Ф.Хөснинең тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрьнең тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә, уку, сүзлек эше, эчтәлек буенча үзара сорау-җавап бирешү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. | 153-154нче бит, эчтәлек. | | |
| 49 | Ф.Хөсни “Бала белән солдат” хикәясәе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, уку, сораулар һәм биремнәр буенча эшләү, текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне табу. Малайның этисенә мәхәббәте чагылышы. Бала психологиясен ачу. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету. | 154-157нче күнегү, эчтәлек | | |
| 50 | Ф.Хөсни “Сөйләнмәгән хикәя” | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Уку, аның төрләре, эчтәлек буенча фикер алышу. Хикәяне анализлау, образлар системасы. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү.Хикәяне анализлый белү. | 158-162нче бит, эчтәлек һәм анализ | | |
| 51 | **“Ялкын” бездә кунакта. Б.с.ү.** | 1 | Материалны ныгыту | “Ялкын” журналы белән танышу. Нәфис һәм фәнни популяр текстларны чагыштыру, журнал битләрендә ориентлашу. | | Сөйләм телен баету**.** | Журналдан бер хикәя укырга. | | |
| 52 | Н.Дәүлинең тормыш юлы, иҗаты. “Бәхет кайда” шигыре. | 1 | Катнаш | Язучының тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә. Сәнгатьле уку, шигырьне анализлау, сурәтләү чараларын табу. | шигырь ятлау | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү.Шигырьне анализлау | 165нче бит, шигырь ятларга. | | |
| 53 | Н. Дәүлинең “Кар нинди җылы” хикәясе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, эчтән уку, төп фикерне аңлау һәм үз сүзләре белән әйтү. Өлкәннәр һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Текст эчтәлегенә карата бирелгән сорауларга җавап бирү. Сөйләм телен баету | 174нче бит, сорауларга җавап | | |
| 54 | **М.Хәсәнов “Шайтан малае” Кл. тыш уку.** | 1 | Материалны ныгыту | Китапка мәхәббәт тәрбияләү, китаплар уку белән кызыксын-дыру, мөстәкыйль укуга күнекте- | | Сөйләм телен үстерү. Әдәби әсәрләр белән эшләргә өйрәнү. | Берәр өзекне сөйләргә | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | рү. Әсәр турында үз фикерен сөйләп бирә белү сәләтен үстерү. | | | | | |
| 55 | Н.Арслановның тормыш юлы, иҗаты. “Казан” шигыре. | 1 | Катнаш | Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә, Казанга мәхәббәте. Сүзлек эше, уку, әңгәмә, җырлар тыңлау. | шигырь ятлау | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Лексиканы белү. Казанның үткәне һәм киләчәген белү. | 176-177нче бит, шигырь ятларга | | |
| 56 | Г.Дәүләтшиннең тормыш юлы. “Гасырлар тирәнлегеннән” | 1 | Катнаш | Сүзлек эше, текстның исемен аңлау, төп фикерне табу, әңгәмә, рәсемнәр карау. | | Татар халкының борынгы тарихы, аны өйрәнү һәм саклау. | 178-181нче бит, эчтәлек | | |
| 57 | Г.Бәшировның тормыш юлы, иҗаты. “Нинди ул Татарстан?” | 1 | Катнаш | Республика турында мәгълүмат бирү, укучылар чыгышы, әңгәмә, рәсемнәр карау, музыкаль әсәрләр тыңлау. | | Татарстан гимны, символикасын белү. Татарстанның үткәнен белү. | 183нче бит, сорауларга җавап | | |
| 58 | С.Сөләймpraвның тормыш юлы, иҗаты. “Кайный, шаулый Казан урамнары”. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Язучының тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә. Казанга бәйле бөек шәхесләр турында өстәмә мәгълүматлар бирү. Сүзлек эше, сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу. | | Казанда яшәгән бөек шәхесләр турында белү. Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьне анализлау. | 185нче бит, сәнгатьле уку | | |
| 59 | Халыктагы ырымнар һәм аларның тормыш-көнкүрештә чагылышы. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Ырымнар турында төшенчә, аларның табигатенә хас төп сыйфатлар; | | Ырымнар турында белү. | Ырымнар язып килергә. | | |
| 60 | Ш.Галиевнең томыш юлы, иҗаты. | 1 | Катнаш | Шагыйрьнең тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә. Мөстәкыйль уку, эчтәлек буенча сорау-җавап бирешү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Хронологик таблица төзү. | Хронологик таблица төзергә | | |
| 61 | Ш. Галиев “Алтын куллар”, “Хәзинә”, “Саумысыз, арышларым”. | 1 | Катнаш | Сәнгатьле уку, шигырьне анализлау , сурәтләү чараларын табу, сорауларга җавап бирү. | Тест, 10мин | Һөнәрле, белемле булуның кеше тормышында әһәмияте. Шигырьне яттан белү | 189нчы бит, шигырь ятларга | | |
| 62 | Ш.Галиев “Телләр белүче каләм”, “Магнитофон онытмый” шигыре. | 1 | Катнаш | Сәнгатьле уку, шигырьне анализлау , сурәтләү чараларын табу, сорауларга җавап бирү. | | Туган телне белүнең кеше тормышында әһәмияте. Шигырьне яттан белү | 191нче бит, шигырь ятларга | | |
| 63 | Р.Батулланың тормыш юлы. “Дуслар дус булып кала” әкияте. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә. Сүзлек эше, уку, эчтәлек буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү. | Дуслык турында әкият язарга. | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Дусларны табу һәм аны саклый белү әһәмияте. Язма сөйләмне үстерү. | Дуслык турында әкият язарга | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 64 | Ф.Яруллинның тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрьнең тормыш юлы Һәм иҗаты турында белешмә. Сүзлек эше, уку, төп фикерне кыскача әйтеп бирү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. | 200-201нче бит, эчтәлек | | |
| 65 | Ф.Яруллин “Анам теле” шигыре. | 1 | Катнаш | Сәнгатьле һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру, сурәтләү чараларын табу, сорауларга җавап бирү. Туган телгә мәхәббәтнең сурәтләнүе. | Тест (10мин) | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү.Шигырьне анализлау | 201-202нче бит, сәнгатьле уку | | |
| 66 | Ф.Яруллин “Кояштагы тап” әкияте. | 1 | Катнаш | Уку, сүзлек эше, фикер алышу, текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне табу. | | Ялганның кешегә начарлык булып кайтуы. Текстның эчтәлеген сөйли белү.Хикәяне анализлый белү. | 202-204нче бит, эчтәлек | | |
| 67 | **“Безнең бакча” темасына сөйләшү. Б.с.ү** | 1 | Материалны ныгыту | Әңгәмә, фикер алышу, сорауларга җавап. | | Сөйләм телен үстерү. Бәйләнешле фикерле белү сәләтен, дөрес җөмләләр төзү осталыгын үстерү. | 205нче бит, сорауларга җавап | | |
| 68 | Солтан Шәмсинең тормыш юлы, иҗаты. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Язучы турында мәгълүмат бирү. Мөстәкыйль уку, эчтәлек буенча сорау-җавап бирешү. | | Язучының тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын истә калдыру. Хронологик таблица төзү. | Хронологик таблица төзергә | | |
| 69 | С.Шәмси “Табигатьнең газиз баласы” хикәясе. | 1 | Яңа материалны өйрәтү | Сүзлек эше, уку, эчтәлек буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү. Табигать турында әңгәмә. Кешене кеше иткән төп сыйфатлар: мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек. | | Лексиканы белү. Текстның эчтәлеген сөйли белү. Хикәяне анализлый белү. | 221нче бит сорауларга җавап | | |
| 70 | **Җ.Тәрҗеманов “Шаян белән Наян”. Кл.тыш уку** | 1 | Материалны ныгыту | Китапка мәхәббәт тәрбияләү, китаплар уку белән кызыксын-дыру, мөстәкыйль укуга күнекте-рү. Әсәр турында үз фикерен сөйләп бирә белү сәләтен үстерү. | | Сөйләм телен үстерү. Әдәби әсәрләр белән эшләргә өйрәнү. | | | |
| | | | | | | | | | |